РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 ноябрь 2022 ел Буа шәһәре № 5-37

ТР Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указы, 2013 елның 25 июнендәге Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 50-ТРЗ номерлы законы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендәге 7-43 номерлы «ТР Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмә» карары белән расланган (2015 елның 15 августындагы 9-50, 09.07.2021-14 номерлы карарлар редакциясендә) ТР Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пункты :

в) пунктчасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

1.2.Нигезләмәнең 6 пункты:

г) пунктчасын белән түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«г) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов